Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнар җыены

К А Р А Р

21.11.2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең
Тихоново авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 4 номерлы карары нигезендә, 2025 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыенында түбәндәге сорау каралды: “2026 елда Сез үзара салым акчаларын I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк затлардан тыш, Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы ядкарен ремонтлау һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (печән чабу, Коммунистлар урамындагы 6, 8, 10 нчы күпфатирлы йортлар янында киртәләр урнаштыру);

4) урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту баганаларын урнаштыру)

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 525 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар санына 284 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе " позициясе өчен 284 граждан тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. 2026 елда Сез үзара салым акчаларын I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк затлардан тыш, Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?" дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы ядкарен ремонтлау һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (печән чабу, Коммунистлар урамындагы 6, 8, 10 нчы күпфатирлы йортлар янында киртәләр урнаштыру);

4) урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту баганаларын урнаштыру)

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Тихоново авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге башлыгы _____________ А.Г. Гәрәева